## Белеп торыгыз

### Реклама урнаштыру гадиләштерелә

Казан шәһәр Думасы "Казан шәһәрендә реклама конструкцияләрен урнаштыру турында" 2009 елның 26 ноябрендә кабул ителгән карарына төзәтмә кертергә булды. Товарлар сату, хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче оешманың урыны (адресы), эш режимы турындагы мәгълүматлар киләчәктә территорияне төзекләндерү элементы исәбенә кертеләчәк. Тышкы мәгълүмат чараларын җирле үзидарә органнары белән килештерү тәртибе дә гадиләштерелде. Әшкуар тышкы мәгълүмат чарасын урнаштырганда башкарма комитетның архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе белән конструкциянең тышкы күренешен генә килештерергә тиеш. Хәзер башкарма комитетның тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсенең рөхсәте кирәкми.

Әгәр бина түбәсенә бер реклама конструкциясе урнаштырылган булса, икенчесен урнаштыру рөхсәт ителми. Реклама конструкциясе хуҗасы язма гариза нигезендә хокукын башка кешегә тапшырса, яңа хуҗа хакындагы мәгълүмат шәһәр реестрына кертелә. Әгәр реклама конструкциясе дәүләт яки муниципаль карамактагы җир кишәрлегендәге бинада урнашкан булса, бина һәм җир кишәрлеге иясе, реклама конструкциясенең элеккеге һәм яңа хуҗасы арасында өчьяклы килешү төзелә.

### Уку йортлары солдатлар әзерли

Элек студентлар махсус кафедралары булган югары уку йортларыннан гына хәрби билет һәм белгечлек алып чыга иде. Киләчәктә мондый мөмкинлектән барлык югары уку йортлары студентлары файдалана алачак.

Русия Федерация Советы тарафыннан махсус кафедралары булмаган уку йортлары студентларына да хәрби әзерлек узу мөмкинлеге бирүче закон проекты эшләнүе, документны Президент Владимир Путинның хуплавы мәгълүм. Илнең югары уку йортларына әлеге яңа система 2014 елның 1 сентябреннән керә. Аның барышында егетләр солдат һәм запастагы сержантлар әзерләү программасы буенча белем алачак. Солдатлар әзерләү программасы – ел ярым вакытка, сержантларныкы ике елга исәпләнгән. Теория үзләштергәннән соң, өч айлык хәрби җыеннар уздырыла. Шушы сынауларны узучыларга рядовой яки запастагы сержант дәрәҗәсе бирелә. Белгечлек алуга ук алар резерв исемлегенә кертелә. Мондый егетләр, уку йортын тәмамлагач, армия сафларына чакырылмый, алар хәрби хезмәтне уку йортында узган санала.

### Вьетнамга – Татарстан кораблары

Яшел Үзәннең М.Горький исемендәге суднолар төзү заводы Вьетнамга ике яңа "Гепард-3.9" төзеп тапшырачак. Заказчыга беренче судно – 2016 елда, икенчесе 2017 елда җибәрелә. Бүген Вьетнам Хәрби-диңгез көчләрендә "Гепард-3.9" проектлы ике кораб хезмәт итә инде.

# Татар хәрәм ашыймы?..

Сәүдә үзәгендә йөреп арыган, ачыккан балаларның тамагын ялгатып алырга булдык. Хәләл ризыклы кафе-фәлән эзләштереп, тирә-юньгә күз салдык. Озак эзлисе дә булмады, "Нәүрүз" ресторанын янына килеп чыктык, аш өенең исеме астына ук "татарская кухня" дип язып куелган. Токмачлы аш ашап, өчпочмаклап чәй эчеп чыгарбыз, дип шатлана-шатлана эчкә үттек. Тик безгә монда тәгам җыю насыйп түгел икән. "Ризык хәләлдер бит?" - дигән сорауга аш өе әһеле "юк" дип башын чайкады. Югыйсә, татар милли ризыклары бары тик хәләл генә була ала. Ләкин, ни кызганыч, татар халкының күпчелек өлеше хәзер хәләлне хәрәмнән аерып мәшәкатьләнми шул. Татар ашларыбызны авыз итүдән өметне өзгәч, якындагы шәрекъ кафесына кереп, үзбәк лагманы белән сумса ашап чыгарга туры килде.

Дөрес, хәзер башкалабызда хәләл ризык әзерли торган кафе, аш өйләре аз түгел. Ләкин аларда татар халкының милли ризыкларын сирәк очратасың. Өчпочмак, пәрәмәчләр эзләп тапсаң да, алар тиешле дәрәҗәдә хасиятләп пешерелми һәм теләгән йотарлык тәмле дә түгел. Моның аңлатмасы да бик гади: хәләл ризык кафеларын еш кына Урта Азияле кардәш халыклар вәкилләре ача һәм алар татар милли ризыкларын пешерә белми. Аның каруы, алар үзләренең лагман, шаурма, сумса, дөнәр кебек ашсуларын бик оста әзерли һәм без аларны яратып ашыйбыз да. Ләкин милли горурлык дигән нәрсә, кая гына тәгам җыярга керсәң дә, менюдан үзебезнең милли ризыкларны эзләргә мәҗбүр итә. Ни кызганыч, урта хәлле кеше кереп, төшке аш ашый яки кичен ял итеп утыра торган кафеханәләрдә ләззәтләнеп ашарлык тәмле милли татар ризыкларын табып булмый. Еш кына өчпочмак пешерсәләр дә, ул олтан кебек килбәтсез камыр тышлык эченә әтрафсыз гына тутырылган бәрәңге-суган катнашмасыннан гыйбарәт бер нәрсә булып чыга. Татар ризыкларыннан тагын токмачлы аш таба аласың. Әә атаклы татар ашлары остасы Юныс Әхмәтҗанов китабына кергән казылык, кыздырма, тутырма, кияү пилмәне, каклаган каз кебек ризыкларны кафеларда бөтенләй табарлык түгел. Болаларын, әлбәттә, рестораннарга кереп авыз итәргә була. "Яндекс"-ның эзләгеч системасы, Казанда татар кухнясы аш-суларын тәкъдим итә торган 212 ресторан бар, дип күрсәтә. Ләкин андагы ризыкларның бәясе шактый "тешле": әйтик, каклаган казның 100 граммы 400-450 сумга төшәчәк. Өстәвенә, рестораннар арасында хәләл сертификатына ия булганнары 2-3 бөртек кенә.

Милли ашларыбызның табыннардан югала баруына борчылып йөреп, үзе татар кафесы ачып җибәргән бик булдыклы Роза ханым Мөслимова белән бу хакта сөйләшкән идек. "Милли ризыкларыбызны әзерли белә торган осталары да калмады ич инде аның, - диде ул. – Кем ничек булдыра, шулай пешерә хәзер. Ашсуга салына торган ризыкларны арзанрак төрләренә алыштыралар. Әйтик, рецептта сыер мае салынырга тиеш, ә аның урынына үсемлек мае кушалар, сары май кирәк, диелгән икән, аны бөтенләй кулланмыйлар, һаман шул үсемлек мае яшәсен. Чабылган итне фаршка алыштыралар... Нәтиҗәдә, милли ризыкларыбызның бөтен үзенчәлеге, ләззәте югала".

Татар аш-су осталарын укыту мәсьәләсе ничегрәк тора соң? Бу хактагы соравыбызга шәһәребезнең кондитерлар һәм аш пешерүчеләр әзерли торган сәүдә-кулинария профессиональ лицеенда "Бездә милли ризыкларыбыз остасы кебек белгечлек юк, федераль стандартлар буенча укытабыз, татар ризыкларны пешерергә өйрәтүче махсус юнәлеш юк", - дип җавап бирделәр.

Татар ашларын сәнгати дәрәҗәгә күтәрә белгән Юныс Әхмәтҗанов эшен дәвам итәр осталар бар инде ул барын. Ләкин алар иҗат иткән чын мөкәммәл милли ашларны рестораннарда гына авыз итеп була хәзер. Болай дәвам итсә, өчпочмак-кыздырмаларыбызның деликатеска әверелеп калуы да бар. Казаныбыз бүген туристларны көннәнкөн күбрәк үзенә тарта. Шәһәрнең туристлык маршрутларында җиренә җиткереп әзерләнгән милли ашларыбыздан гына торган менюлы кафелар – аш өйләре булдырасы иде. Югыйсә, Казанга килгән мосафирларны чәйләтеп чыгарырга урын таба алмый аптырап бетәсең: хәләл кафега керсәң, ләззәтле татар милли ризыгы тапмассың, рестораннарда әзерләнгән милли ризыклар еш кына хәләл түгел, инде хәләл булып чыкса да, кесәгә сугарлык кыйммәт.

Без бала чакта ук Татарстан урамында "Кыстыбый" дип аталган кафе эшләп килде, анда милли аш-суларыбыздан авыз итеп була иде. Шул әллә ничә дистә ел эшләгән, инде мәңге эшләр кебек тоелган "Кыстыбый" кафесын ябып, урынына ниндидер "Шаурма" сыман үзбәк ашханәсе ачып куйдылар. Һәр чат башындагы чәйханәдә чыжылдап пешеп утырырга тиешле пәрәмәчне эзләп ресторанга барырга кирәк хәзер. Татар баеса, чабатасын түргә элә, ди. Ә читтән килгәннәр тәкәбберләнеп тормый: сәүдә дә итә, үз ризыкларын пешереп, безне ашата да...

Милли ризыклар - ул милли кием, милли җыр-көйләр, туган тел кебек үк, милли рухны тәшкил итүче бер кыйтга лабаса. Татарга һәрвакыт хәләл һәм милли ризыклар җыярга насыйп булсын иде.

**Эльмира СИРАҖИ.**

## Күргәзмә залларында

# "Манзара" үткәннәргә кайта



КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының "Манзара" күргәзмәләр залында рәссам Булат Гыйльванов эшләреннән "Үткәннәргә кайту" дигән күргәзмә ачылды.

Булат Гыйльванов1972 елны Алабуга шәһәрендә дөньяга килгән. 1980-87 нче елларда каланың И.Шишкин исемендәге сәнгать мәктәбендә укый. 1991 елны Чаллы сәнгать училищесының сәнгать бүлеген тәмамлый. 1997 елны И.Репин исемендәге Санкт-Петербург дәүләт сынлы сәнгать, скульптура һәм архитектура институтының графика факультетында гыйлем ала. 2001-2005 елларда Русия Сәнгать академиясенең иҗат һөнәрханәсендә рәссам-стажер булып эшли. 2002 елдан - Русия Рәссамнар берлеге әгъзасы. 2003 елда ул "Йосыф кыйссасы" дигән рәсемнәр сериясе өчен Б. Урманче исемендәге бүләккә, ә 2007 елда "Алтынчәч" картиналар циклы өчен М.Җәлил исемендәге Республика премиясенә лаек була. Аның эшләре Русия, Англия, Төркия, Германия, Япония, АКШ кебек илләрнең дәүләт коллекцияләрендә һәм шәхси тупланмаларда саклана.



Б.Гыйльванов эшләре тематик һәм стилистик яктан күптөрле. Әмма аның иҗатында бер-берсенә капма-каршы һәм шул ук вакытта бер-берсен тулыландырып торган ике юнәлешне анык күрергә мөмкин. Беренчесе - тарихи рәсемнәрне үз эченә алган реалистик юнәлеш. Бу юнәлештә тарихи һәм археологик материал файдаланыла, романтизм стиле кулланыла һәм детальләштерү хас. Моңа мисал итеп "Алтынчәч" картиналар сериясен китерергә була. Икенче юнәлеш Аурәзия халыклары, борынгы төрки, татар халкы сәнгатьләрен өйрәнеп, оригиналь образлар системасын һәм сурәтләү телен булдыру. "Кәләш", "Җир җиләге", "Шикәр кисәге", "Йосыф кыйссасы" сериясе һ.б. әнә шул өслүбтә иҗат ителгән. Рәссамның иҗат бәйрәменә Филология, мәдәниятара багланышлар институты укытучылары, студентлар һәм кунаклар килгән иде. Күргәзмәне ФМБИ директоры Р.Җамалетдинов ачты. Ул Б.Гыйльванов иҗатына югары бәя бирде һәм әлеге күргәзмәнең студентлар теләге буенча оештырылганлыгын әйтте. ФМБИның С.Сәйдәшев исемендәге югары сәнгать мәктәбе мөдире З.Явгильдина исә рәссам иҗатының тематик яктан отыры төрлеләнә баруы турында әйтте. Ул шулай ук, Булатка студентларны сынлы сәнгать серләренә өйрәтү турында да уйланырга киңәш итте.

Сынлы сәнгать һәм дизайн кафедрасы мөдире Р.Сәлахов, шушы ук кафедра доцентлары М.Яо, В.Вәлиуллин Б.Гыйльвановның милли юнәлештә иҗат итүче монументалист булуын билгеләп үтте.

Күргәзмәне ачу тантанасында халыкара һәм Бөтенрусия конкурслары лауреатлары, С.Сәйдәшев исемендәге югары сәнгать мәктәбе студентлары Динар Габдрахманов һәм Сиринә Нурисламова чыгыш ясады.

Б.Гыйльванов үз чыгышында "Манзара" күргәзмә залын булдырганнары һәм үз иҗатына игътибар итеп, күңелле оерашу үткәргәннәре өчен ФМБИ җитәкчелегенә рәхмәт белдерде. Ул алга таба да милли юнәлештә һәм бигрәк тә этнофутуризм стилендә эшләячәген белдерде. Этнофутуризм – этник мәдәният традицияләренә нигезләнгән хәзерге заман сәнгате стиле. Әлеге фикерен куәтләп, рәссам: "Мин татар халкының милли мәдәниятен өйрәнә башлагач, үземне яхшы мәгънәдә космополит итеп тоя башладым. Үз халкың традицияләрен башка халык традицияләре белән чагыштыра башлагач, аларның кардәш булуына, бер чыганактан икәнлегенә төшенәсең", – диде.

**Ренат МИҢНЕГАЛИЕВ.**